| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЛЕНИНОГОРСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» | «ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 елның 14 июле № 657

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының ««Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр күләмнәрен һәм күрсәтелгән керемнәрдән хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәрен, максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, 2021 елга план күрсәткечләрен билгеләү турында» 2020 елның 24 декабрендәге 1484 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр күләмнәренең план күрсәткечләрен һәм күрсәтелгән керемнәрдән хезмәт хакын түләүгә юнәлдерелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәрен, максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, 2021 елга план күрсәткечләрен билгеләү турында» Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинетының 2020 елның 11 декабрендәге 1130 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 8 июлендәге 546 номерлы карары нигезендә, «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының ««Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр күләмнәрен һәм күрсәтелгән керемнәрдән хезмәт хакы түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә торган күләмнәрен, максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, 2021 елга план күрсәткечләрен билгеләү турында» 2020 елның 24 декабрендәге 1484 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Түбәндәге эчтәлектәге 1.1 пункт белән тулыландырырга:

«1.1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең бюджет учреждениеләре тарафыннан административ-идарәче персоналның хезмәт хакын түләүгә күрсәтелгән учреждениеләр тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрдән юллана торган чыгымнар күләме әлеге карарның 1 пункты нигезендә хезмәт хакын түләүгә җибәрелә торган күрсәтелгән керемнәр күләмене, әлеге карарның 1 пункты нигезендә, 30 процентыннан артыграк була алмый дип билгеләргә.».

2. Әлеге карар 2021 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

Р.Х. Хәмидуллин
5-18-25